**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

Аксубай районының Иске Үзи авылындагы Горький урамы;

Әлки районының Базарлы Матак авылындагы Луговая урамы;

Әлки районының Иске Әнҗерә авылындагы Дальняя урамы;

Апас районының Апас шәһәр тибындагы поселогында Җамал Вәлиди урамы;

Биектау районының Дөбъяз авылындагы Төзүчеләр урамы;

Саба районының Югары Шытсу авылындагы Комсомол урамы;

Спас районының Болгар шәһәрендәге Нагаев урамы;

Балык Бистәсе районының «Кызыл Йолдыз урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесе Арыш участок урманчылыгының 25 нче кварталы.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 23 мартындагы ПУ-307 номерлы Указы 1 пунктының икенче – тугызынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 25 май
№ ПУ-486

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ